**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-48 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 21 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 29 май
№ 357

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 29 » маендагы
357 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең**
**Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында**
**нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе (алга таба шулай ук – Идарә) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора, турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

2. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Идарә турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

II. Идарәнең төп бурычлары

4. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы мәгълүмат сәясәте һәм мәгълүмати куркынычсызлык мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе кушуы буенча әлеге тәкъдимнәрне гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә тиешле докладлар әзерләү максатларында Татарстан Республикасында сәяси процесслар барышы, республиканың социаль-икътисадый үсеше, тышкы элемтәләре, булачак зур чаралар ягыннан чыгып караганда, мәгълүмати мәйданны мониторинглау, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмаларны мониторинглау;

мәгълүмати мәйданда әһәмиятле темаларның үсешен фаразлау;

вакыйгалар буенча мәгълүмат җиткерүне планлаштыру;

республика башкарма хакимият органнары белән иҗтимагый-сәяси чараларны мәгълүмати тәэмин итү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү;

мәгълүмати мәйданда Татарстан Республикасын танытуга юнәлтелгән проектларны координацияләү.

III. Идарәнең төп функцияләре

5. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

социаль әһәмияткә ия мәсьәләләр һәм Татарстан Республикасында гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган органнар эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мәгълүмати мәйданны мониторинглау;

үз компетенцияләре чикләрендә вәкаләтле органнар белән бергәләп Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә массакүләм мәгълүмат чараларындагы, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча басмаларга һәм хәбәрләргә күзәтү әзерләү;

Татарстан Республикасының мәгълүмат өлкәсендәге сәясәте һәм аның мәгълүмати куркынычсызлыгы өлкәсендә четерекле сорауларга һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәргә кагылышлы аналитика материаллары әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә җәмгыять тормышының сәяси, социаль-икътисадый, дини, мәдәни өлкәләре үсешенә кагылышлы мәгълүмат мәйданының төрле ресурсларында чагылыш тапкан тенденцияләр турында мәгълүмат бирү;

Идарә компетенциясе чикләрендә мәгълүмат чараларын һәм мәгълүмат кампанияләрен оештыру;

социаль әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча контентка мәгълүмати мәйданда этәргеч бирү механизмнарын булдыру һәм камилләштерү мәсьәләләрен күтәрү;

Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Рәисе катнашындагы чараларны, аның әйдәүче профильле белгечләр һәм экспертлар, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм челтәр берлекләре белән очрашуларын әзерләүдә башлап йөрү һәм аларда катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенең Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәкаләләре, мөрәҗәгатьләре һәм чыгышлары тезисларын әзерләү;

Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары, беркетмәләре һәм йөкләмәләре проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыкларын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләрен үтәү буенча үз компетенцияләре чикләрендә тәкъдимнәр әзерләү;

республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең башка структур бүлекчәләре белән берлектә Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасы, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисенең чыгышлары өчен материал җыю, анализлау һәм әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисенең иҗтимагый әһәмияткә ия булган чараларда, очрашуларда, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисенең эш сәфәрләре вакытында чыгышлары текстлары һәм тезислары проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең башка структур бүлекчәләре белән берлектә Татарстан Республикасы өчен актуаль мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары өчен төрле материаллар әзерләү.

Идарә Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәләре буенча башка функцияләр башкара.

## IV. Идарәнең хокуклары

6. Идарә үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тикшеренүләр, конференцияләр, семинарлар, конкурслар һәм башка чаралар уздырырга;

Идарә компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тематик мәгълүмати-белешмә һәм аналитик материаллар, күзәтүләр, шул исәптән электрон рәвештә дә, чыгарырга;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Идарә компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча эшне камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр кертергә.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

7. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Идарә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, башка оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

8. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте булмаган вазыйфалар биләүче Идарә хезмәткәрләре хезмәт законнары нигезендә җаваплы була.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

9. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

10. Идарә эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе указы белән вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) җитәкчелек итә.

11. Идарә башлыгы:

Идарә эшен оештыра, Идарәгә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

Идарәнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Идарә хезмәткәрләре арасында хезмәт бурычларын бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын һәм вазыйфаи инструкцияләрен раслауга тапшыра;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарәнең структурасы, штат саны, Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм биләгән вазыйфасыннан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашу өчен Идарә вәкилләрен җибәрә.

12. Идарә җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаганда, аның вазыйфаларын Идарә башлыгы урынбасары яисә Идарәнең башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

13. Идарә хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

---